| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2020 пгт. Рыбная Слобода № 43пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 гыйнварындагы 25 пи номерлы карары белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 гыйнварындагы 25 пи номерлы карары белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, Россия Федерациясе законнарында | Гаризаны теркәгәннән соң 14 календарь көн эчендә.<br>Элек расланган шәһәр төзелеше планының дубликатын бирү гариза кергән көннән алып 4 көн эчендә, ләкин 10 календарь көннән дә артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | РФ ШрК 57.3 ст.6 ө. |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, аны туктатып тору вакыты | | |

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д. Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р. Л. Исланов